ГЛАВА
МАЙНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАЙНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**КАРАР** с.Верх.Тат.Майна **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**30.10.2019** **№ 15**

**Алексеевск муниципаль районының “Майна җирлеге территориясендәге Югары Татар Майнасы авылында үзара салым кертү һәм гражданнарның үзара салым акчаларыннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында “**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ” Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында “Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы», Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә,

**Карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районының Майна җирлеге территориясендәге Югары Татар Майнасы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2019 елның 10 нчы ноябре көнне 10 сәг 00 минутта гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
Алексеевск муниципаль районы Майна җирлеге территориясендәге Югары Татар Майнасы авылында 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, үзара салымны, барлык шул җирлек территориясендә теркәлгән, балигъ булган затлардан, хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку бүлеге студентларыннан тыш, җыюга һәм акчаларны җирле түбәндәге мәсәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы?

- урам утларын карап тоту;
- җирлек эчендәге юлларга вак таш җәю, төзекләндерү һәм карап тоту;

“ ӘЙЕ " КАРШЫ”

3. Халык җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Җыенның үткәрү урыны дип авыл мәдәният йортын билгеләргә. Адресы: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Югары Татар Майнасы авылы, Тау урамы, 15 нче йорт.

5. Әлеге карарны Майна авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Югары Татар Майнасы авылы, Тау урамы, 15 нче йорт адресындагы мәгълүмат стендында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Майна авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** **Р.Н.Гафиятуллин**